**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлегенең Биләркүл авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«22» ноябрь 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биләркүл авыл җирлегенең Биләркүл авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Биләркүл авыл җирлеге Биләркүл торак пункты территориясендә яшәүче, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Биләркүл авылы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны яктырту җайланмасы.

Халык җыенында рәислек итүче: В.С. Оренбургов

Биләркүл авыл җирлеге башлыгы: В.С.Оренбургов